**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

01.07.2017 № 414

**Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өч яклы комиссиясе координаторы турында**

«Татарстан Республикасында социаль партнерлык органнары турында» 2004 елның 26 июлендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, «Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе» берлеге һәм Татарстан Республикасы Предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе (эш бирүчеләрнең төбәк берләшмәсе) тәкъдимнәрен исәпкә алып:

1. Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Нигъмәтуллин Рөстәм Камил улын Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өч яклы комиссиясе координаторы итеп билгеләп куярга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өч яклы комиссиясе координаторы турында» 2014 елның 3 декабрендәге 679 номерлы боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**